РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 191

2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында», 278-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт (муниципаль) бурычлары, Россия Федерациясенең дәүләт (муниципаль) бурычлары һәм дәүләт финанс активлары белән идарә итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү турында» Федераль законнары, Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «Дәүләт һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең эмиссия һәм мөрәҗәгате үзенчәлекләре турында» Федераль законның, 2019 елның 2 августындагы 307-ФЗ номерлы «Бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның көчен югалтуын тану нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге нигезләмәнең 14-15.12, 16.1-16.6 статьялары Район бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына

бюджеттан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә»;

Нигезләмәнең 15.5 статьясында «Чаралар гамәлгә ашырыла торган Район өчен» сүзтезмәсен «Районга карата чаралар күрелгән очракта» сүзтезмәсенә алмаштырырга.

2. Әлеге Карарны Интернет челтәренең мәгълүматый-телекоммуникацион «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин